**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.40,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 40
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

1 октябрь 2018 ел №45-107

# ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БИЛӘМӘСЕНДӘ ҮЗАРАСАЛЫМ ҖЫЮ ҺӘМ КУЛЛАНУ БУЕНЧА ҖИРЛЕ РЕФЕРЕНДУМ ҮТКӘРҮ КӨНЕН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 131 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Шахмай авыл җирлеге Уставының 11 маддәсе, Шахмай авылы җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендә чыккан 21 нче номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Шахмай авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 сентябрендә чыккан 44-106 нче номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

**ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Шахмай авыл җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча 2018 елның 18 нче ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда карaласы мәсьәлә:

1. " Сез Шахмай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 500 сум күләмендә үзарасалым җыю белән килешәсезме? Үзарасалым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларның тол хатыннары, 1 группа инвалидлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, 75 яшьтән өлкән ялгызаклар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

- авыл юлларын җәйге (юл кырыйларын чабу) һәм кышкы (урамнарны кардан чистарту) чорларда тәртиптә тоту; Шахмай, Чаллы Башы һәм Чертуш авыллары чикләрендә урам юлларын төзекләндерү, тәртиптә тоту;

- Шахмай һәм Чаллы Башы авылларында урнашкан санкцияләнмәгән ККК чүплеген юк итү;

- суүткәргеч линиясендәге җитешсезлекләрне төзәтү һәм тәртиптә тоту, Шахмай, Чаллы Башы, Чертуш авылларына 3 данә тирәнлек насосы алу;

- Шахмай авыл җирлеге биләмәсендәге биологик калдыкларны җыю һәм туплау урынын тәртиптә тоту.

ӘЙЕ ЮК

2. Карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча “Яңа Чишмә хәбәрләре" район газетасында басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карар үзкөченә басылып чыкканнан соң керә.
4. Карарның башкарылуын контрольдә тотуты үз өстемә йөклим.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов